Республика Татарстан
Исполнительный комитет
Камаевского сельского поселения
Менделеевского муниципального
района

423643,РТ, Менделеевский район,
с.Камаево, ул. Дифгата Сирая д.29А

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Камай авыл җирлеге
башкарма комитеты

423643 , РТ, Менделеевск районы,
Камай авылы, Дифгать Сирай
урамы 29А йорты

Тел./ факс: 8(85549) 3-55-33, E-mail: Kam.Men@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2021 елның 9 нчы апреленнән 6 номерлы

Белешмә (өземтә) бирү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына
үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында "Федераль законның 7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында" 2016 елның 19 декабрендәге 433-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә"» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Камай авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге Башкарма комитетының 23.05.202020 ел, № 8 карары белән расланган белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 бүлекнең 2.5 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен законнар яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләрнең тулы исемлеге, аларны мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе | Муниципаль хезмәт алу өчен гариза бирүче түбәндәге документларны тапшыра:<br>1) шәхесне раслаучы документ;<br>2) мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ, мөрәҗәгать итүче вәкиленең муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта (физик затларның законлы вәкилләреннән тыш);<br>3) гариза:<br>- документ формасында кәгазьдә (кушымта № 1); | |

| | | |
|---|---|---|
| | - Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә «Электрон имза турында» 06.04.2011 ел, № 63-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган электрон формада (интерактив формага тиешле мәгълүматларны кертү юлы белән) тутырыла;<br>4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүче булмаган затның персональ мәгълүматларын эшкәртү кирәк булса һәм әгәр федераль закон нигезендә мондый персональ мәгълүматларны эшкәртү күрсәтелгән затның ризалыгы белән башкарыла ала икән, Муниципаль хезмәт алу өчен мөрәҗәгать иткәндә мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән затның яисә аның законлы вәкиленең шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгын алуны раслаучы документларны өстәмә рәвештә тапшыра. Рөхсәт алуны раслаучы документлар, шул исәптән, электрон документ формасында да тапшырылырга мөмкин;<br>5) йорт кенәгәсен саклау бурычы 31.12.2017 кадәр торак биналарның милекчеләренә йөкләнгән булса, гариза бирүче тарафыннан йорт китабы тапшырыла;<br>6) шәхси торак йортка хокук билгели торган документлар (әгәр милек хокукы күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән булса) - хуҗалык кенәгәсеннән өземтә өчен.<br>Муниципаль хезмәт алу өчен гариза бланкын гариза бирүче Башкарма комитетта шәхси мөрәҗәгать иткәндә алырга | |

| | | |
|---|---|---|
| | мөмкин. Бланкның электрон формасы Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм кушып бирелә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:<br>- шәхсән (гариза бирүче исеменнән ышанычнамә нигезендә эш итүче зат);<br>- почта аша.<br>Гариза һәм документлар шулай ук гариза бирүче тарафыннан Республика порталы аша электрон документлар рәвешендә тапшырылырга мөмкин (җибәрелгән). | |

1.2. 1 нче кушымтаны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1 нче кушымта

______________________________________________
(муниципаль берәмлекнең

______________________________________________
җирле үзидарә органы исеме)
(кемнән)__________________________________________
__________________________________________________
(алга таба - мөрәҗәгать итүче (фамилиясе, исеме,
атасының исеме, паспорт мәгълүматлары,
яшәү урыны буенча теркәлү, телефон)

**ГАРИЗА**
**белешмә (өземтә) бирү турында**

Сездән __________________________________________ белешмә (өземтә) бирүегезне сорыйм.
(белешмә төрен күрсәтергә)

Адрес:_______________________________________________________________________________

Гаризага түбәндәге сканерланган документлар теркәлә:

1. ___________________________________________________________________________________

2. ___________________________________________________________________________

3. ___________________________________________________________________________

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында түбәндәге ысул белән хәбәр итүегезне сорыйм ____________________________________

_____________ ___________ ______________________________________

(дата) (имза) (ФИО)

1.3. 2 нче кушымтаны гамәлдән чыгарырга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында - http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштырырга һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында - www.mendsleevsk.tatar.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Камай авыл җирлеге Башлыгы И.И.Әһлиева